Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 11 (11)

15 декабрь 2011 ел

## • Атнаның җиде вакыйгасы

9 декабрь көнне Н.И.Лобачевский истәлегенә багышлап ел саен уздырыла торган фәнни конференция булды. Әүвәл Фәнни китапханә директоры Евгений Струков китапханә хезмәткәрләре Елена Чижанова һәм Маргарита Веселицкаяга РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамоталарын тапшырды. Фәнни-библиографик бүлек җитәкчесе Юлия Лексина Акт чыгышлары турында әчтәлекле, кызыклы, күләмле материал тәкъдим итте. Университетта тәүге тантаналы акт 1805 елның 9 июлендә беренче уку елы тәмамлангач уздырылган. «Казан университеты һәм 1812 елгы сугыш» темасын шул бүлекнең төп библиографы Светлана Ежова яктыртты. Ул студент һәм укытучылар тормышында сугыш афәте, аннан соңгы еллар турында сөйләде.

• • • •

10 декабрь көнне КФУда Мәгълүмати технологияләр һәм хисаплау математикасы институтының программалаштыру буенча V ачык олимпиадасы төгәлләнде. Ул ике турда узды. Интернет турда 129 команда составында 400 кеше катнашты. Икенче турында Казан югары уку йортлары студентларыннан тыш, Идел буе дәүләт университеты (Самара) командасы да көч сынашты. Олимпиададагы төп өч урынны да Казан (Идел буе) федераль университетының Мәгълүмати технологияләр һәм хисаплау математикасы институты студентлары алды.

• • • •

11 декабрь көнне КФУның Алабуга филиалында яңа проект – «Балалар университеты»н ачу тантанасы узды. Чарада 700 дән артык кечкенә студент һәм аларның әти-әниләре катнашты. Проект үзе Казанда ноябрь аенда ачылды. «Балалар университеты» – ул хәйрия эше, бу очракта төп миссиясе – җәмгыятьтә белем алуны алга җибәрү. Икенче төп максаты булып талантларны, Ватаныбыз патриотларын үстерү тора. Алабуга филиалына безнең проектка кушылу мөмкинлеге бирелде һәм ул ышанычны аклады», – диде ректор Илшат Гафуров. Яңа студентларга беренче лекцияне КФУның Тарих институты директоры Валерий Летяев укыды. Ул проектның ата-аналар өчен зур терәк булачагын, ә балаларга үз юлларын табарга ярдәм итәчәген әйтте. Ата-аналарны бирелдә бернинди дә зачет-имтиханнар булмаячак дип тынычландырды.

• • • •

Кичә Казан федераль университетының Геология музеена Татарстан Республикасы территориясенә төшкән бишенче метеоритны тапшырдылар. Метеорит кисәгенең авырлыгы – 5 килограмм. Музейда моңа кадәр инде дүрт метеорит бар иде.

• • • •

Бүген, ягъни 15 декабрь көнне «УНИКС» концертлар залында «Беренче курслар көне – 2011» шәһәр конкурсының гала-концерты уза. Биредә Казан шәһәре уку йортларының иң яхшы иҗат коллективлары чыгыш ясый.

• • • •

Бүген КФУның Университет тарихы музеенда физика фәне буенча Нобель премиясе лауреаты, җәмәгать эшлеклесе, РФ Дәүләт Думасында КПРФ фракциясе депутаты Жорес Иванович Алфёров белән очрашу уза.

• • • •

15-16 декабрь көннәрендә Филология һәм сәнгать институтының «Аль-Хадара» гарәп мәдәнияте үзәгендә ТР Президенты каршындагы тышкы элемтәләр департаменты Марокко Патшалыгы илчелеге белән берлектә уздыра торган «Гарәп мәдәнияте көннәре» фестивале үтәчәк. Ул быел Марокко Патшалыгы көннәренә багышлана. Фестиваль кысаларында Марокко эшләнмәләре, «Мароккога сәяхәт» картиналар күргәзмәсе, «Милли Марокко костюмнары» модасын күрсәтү, гарәп теле буенча олимпиада, татар, рус, марокко халык биюләре һәм җырларыннан концерт була. Шулай ук КФУ һәм «Әбдел Мәликә Әс-Саади» университеты арасындагы аңлашу Меморандумына кул куелачак.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




tatarstan.ru

# КФУда идеяләр күп!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

**Кичә «Корстон»да «Татарстан Республикасы өчен 50 иң яхшы инновацион идея» конкурсы җиңүчеләрен тәбрикләү тантанасы үтте. Чарада ТР Президенты Рөстәм Миннеханов та катнашты.**

Конкурс тарихында җәмгысе катнашырга теләк белдерүчеләрдән җиде меңнән артык гариза кабул ителгән, 754 җиңүче билгеләнгән. Инде жиденче тапкыр үткәрелгән әлеге бәйгенең, Илбашы сүзләренчә, төп максаты – инновацион процесска яшь буынны тарту.

2011 елда 8 номинация буенча үткән бу конкурска 1696 гариза кабул ителә. Шулар арасыннан экспертлар советы 180 җиңүчене аерып чыгара. «Россиянең инновацион төбәкләре ассоциациясе проектлары» дип аталган яңа номинация дә шактый кешене җәлеп иткән. Тик иң күп гариза наносистемалар һәм материаллар индустриясе, авыл хуҗалыгы, экология, азык-төлек җитештерү сәнәгате h.б. өлкәләргә карый. Куркынычсызлык һәм терроризмга каршы көрәш юнәлешендә бары тик 9 гариза кабул ителгән.

Әлбәттә, бүләкләнүчеләр арасында безнең Казан (Идел буе) федераль университеты студентлары һәм галимнәре дә шактый иде. Айрат Фәрид улы Хасьянов (FOSS Labs технологияләре лабораториясе), Тимур Илдар улы Абдуллин (Биохимик сенсорлар), Руслан Әлим улы Кемалов (Композицион битум материаллары), Олег Николаевич Лопатин (Зәркәнбизәү ташларын камилләштерү), Олег Евгеньевич Аникеев (Нуклеин кислоталары бүленеше), Әлим Фәйзрахман улы Кемалов (Битум җитештерү юллары), Оксана Викторовна Бондарь (Молекулалар активлыгын гидролизацияли торган ДНКны билгеләү) әнә шундыйлардан.

## • Алар бездә укыган

# Илһамым - туган ягым

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

**14 декабрь көнне КФУның Филология һәм сәнгать институтында талантлы шагыйребез, М.Горький һәм Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, Ленин һәм Октябрь революциясе ордены иясе Сибгат Хәкимне искә алу кичәсе узды.**

Чарада шагыйрьнең улы, ТРның атказанган фән эшлеклесе, язучы, сәясәтче Рафаил Хәкимов, профессорлар Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, Флёра Сәйфуллина, Миңгол Галиев һәм бүлекнең башка укытучылары, студентлар катнашты.

Быел җөмһүриятебездә бөек Тукаебыз елы уңаеннан бик күп чаралар оештырылды. Алай гына да түгел, әдәбият, мәдәният, сәнгать күгендә якты йолдыз булып балкучы шәхесләребез зур юбилейларын билгеләп узды.

**Ахыры 2нче биттә.**



Ленар Мөхәммәтшин фотосы

● Алар бездә укыган

# Илһамым - туган ягым

**Башы 1нче биттә.**



Рәсемдә: С.Хәким (уртада) Г.Ахунов, М.Садри, композитор С.Садыйкова белән

Халык иҗаты, халык җырлары һәм Тукай поэзиясе традицияләре җирлегендә яза башлаган шагыйрьләрнең берсе Сибгат Хәкимнең тууына 100 ел тулды.

Талантлы шагыйребез С.Хәким 1911 елның 4 декабрендә Әтнә районы Күлле Киме авылында крестьян гаиләсендә туа. Балачагы һәм яшьлеге авыл табигатендә, киеренке хезмәт атмосферасында үтә. Ул Күлле Кимедә беренче тапкыр Тукай әкиятләрен тыңлый, шигырьләрен укый. Илһамны да туган ягыннан ала. Иҗатының төп өлешен туган җиргә, туган нигезгә мәхәббәт хисләре алып тора. Кичәнең «Илһамым – туган ягым» дип аталуы юкка түгел. Бөек шагыйрьгә дә мәхәббәте чиксез аның. Тукай С.Хәкимне халык рухына алып керә, үз җиренә, үз теленә бик нык бәйли. Яраткан шагыйребезнең безнең уку йортында белем алуы – зур горурлык. Ул 1937 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый.

Чарада Сибгат Хәким турында яңгыраган истәлекләр студентлар өчен кыйммәтле мәгълүмат булды. Биредә аның белән шәхсән таныш кешеләрнең һәркайсы җылы эчтәлекле чыгыш ясады. Тәлгат Галиуллин Сибгат Хәким иҗатына тулы анализ бирде. Аның белән ничек танышуы, холык-фигыле турында сөйләде. Алабуга дәүләт педагогия институтында эшләгән дәвердә булган истәлекләрне кунаклар, студентлар игътибарына тәкъдим итеп: «Сибгат ага студентларны бик ярата иде. Әгәр бүгенге көндә исән булса, килеп керер иде дә сезнең белән рәхәтләнеп аралашыр иде. Кечкенә генә буйлы, юмор хисле Сибгат абый яшьләр янында һәрвакыт үсеп китә иде. Алабугага да бик теләп һәм еш килде. Юлсыз, машинасыз заманалар булуга карамастан, үзе белән иҗатташ дусларын алып килеп, студентларга зур бәйрәм ясый иде», – диде.

Кичә студентлар башкаруында шигырьләр, халкыбызның яраткан җырчысы Миңгол Галиев, сәнгать бүлеге студентлары башкаруында Сибгат Хәким сүзләренә язылган җырлар белән үрелеп барды. Миңгол абый яраткан шагыйребез турында бик матур хатирәләр белән дә бүлеште. «Әдәбият галимнәре аның иҗаты турында озак итеп сөйли алса, мин аның җырларын бер туктамыйча җырлый алам», – диде. Сибгат Хәкимнең улы Рафаил әфәнде, әтисен зурлап, бу кичәне оештыручыларга рәхмәт сүзләре җиткерде.

Аның иҗаты - халык күңеле көзгесе. Шигырьләренең һәр юлы халык фикере, хисе, моңы белән сугарылган. Чөнки ул үзе халыкның әдәбен, мәдәни мирасын, көрәш тарихын, өмет-хыялларын бик яхшы белә. Шуңа да аны үз шагыйребез - халык шагыйре дип атыйбыз.

# Ел укытучысын билгеләдек

**Айгөл ҖӘЛӘЛОВА,**
юридик факультет студенты

Халыкара юристлар көне 3 декабрь диеп саналса да, бер атна буе бәйрәм иттек, дигәндәй. Юридик факультет һөнәри бәйрәмен 8 декабрь көнне уздырды. «УНИКС» концертлар залында студентлар, укытучылар, аспирантлар һәм университетны инде бик күп еллар элек тәмамлаган юристлар җыелган иде.

Кичә зур масштаблы булуы белән генә түгел, ә тәүге тапкыр уздырылган «Ел укытучысы» премиясенең нәтиҗәләре белән дә шаккатырды. Номинацияләр буенча тавыш бирү студентлар җилкәсенә салынган иде. Бу процесс берничә атна дәвамында университет сайтында барды. Укырга килгән саен, кызларның чатта: «Менә шушы укытучы алда бара. Кайтып тавыш бирегез, башкасы җиңсен», – диюләрен ишетү кызык иде.

Номинантларга мактау хатлары һәм бүләкләр белән беррәттән, тиздән җитәчәк Яңа елның символы – тасмалы кечкенә чыршы да тапшырылды.

Номинацияләр төрлелеге, деканыбыз Илдар Тарханов әйткәнчә, «күпмәгънәлелеге белән дә аерылып тора» иде. Шулар арасында «Иң гадел» (Ольга Низамиева), «Иң демократик» (Арсен Балафендеев), «Иң кәттә» (Максим Воронин), «Иң креатив» (Максим Васильев), «Спорт сөючән һәм иң актив» (әлбәттә инде, сәхнәгә дә спортчыларча йөгереп менгән Анатолий Шалимов), «Бөтен студенткаларга да ошый» (Вадим Шарифуллин), иң куркыныч һәм көтелмәгән номинация «Беренче тапкырдан тапшыру мөмкин түгел» (Марат Фетюхин), «Тамашачылар игътибарын яулаган» (Зөһрә Гадыльшина), үзенең акыллылыгы белән тамашачыларны басып кул чабарга мәҗбүр иткән «Факультет зирәге» номинациясе җиңүчесе – Борис Железнов, иң күп тавышлар җыеп, студентларның күңелләренә кереп калды. Тулаем алганда, һәрберебез яраткан укытучыбыз өчен җан атты. Ә юридик факультетта һәрбер укытучы да көчле һәм акыллы, җиңүгә лаек. Шуңа өстәп, бик талантлы да әле, һәрберсе дә. Шигырьләр язып, китап бастыру дисеңме, видеога төшеп, җырчыларга импровизацияләр күрсәтү, бию, җырлау дисеңме...

Мәсәлән, Лилия Бакулина катнашкан клип бөтен кешенең дә күңеленә хуш килде. Социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректор Ариф Межведилов башкарган кавказ биюе бәйрәмне тагын да кабызып, залны җанландырып җибәрде.

Яраткан факультетыбызның туган көненә студентлар да бик күп чыгышлар әзерләгән. Азат Гафуров башкаруындагы җыр, «Индекс-8» төркеме биюе, «Мгновение» театр бию коллективы, «Дорога из города» биючеләре, «Ритмы гор» бию төркеменең кавказ халык биюләре – һәммәсе дә югары дәрәҗәдә әзерләнеп, юристларның талантларын тагын бер кат ассызыклады.

Бәйрәм «Люксор» төнге клубында дәвам итте. Икенче көнне укытучылар белән студентлар университетка бара алдымы-юкмы – тәгаен әйтә алмыйм, тик бәйрәм бик шәп узды һәм юристлар чыннан да ял итә белә. Монысы – 100%. Юрфак – Чемпион!

● Табигать сагында

**Энҗе ИБРАҺИМОВА,**
хәбәрче

Күптән түгел университетыбызда әйләнә-тирәне саклау һәм яхшырту буенча өр-яңа хәрәкәт башланып китте.



Миләүшә Гайнетдинова фотосы

«КФУ – чисталык һәм ямьлелек сагында» дип атала ул. Студентлар университет җирлегенә генә түгел, якын-тирә Казан урамнары һәм паркларына да игътибар бирми калмады. Бергә-бергә алар инде күп кенә ташландык һәм игътибарсыз калган почмакларга җан өреп тәртипкә китерде. Шул уңайдан университет җитәкчелеге дә студентларның намуслы эшләренә җавапсыз калмады. 13 декабрь көнне иң активларны Студентлар профсоюзы комитеты җитәкчесе урынбасары Чулпан Галиева мактау кәгазьләре һәм тәмле күчтәнәчләр белән бүләкләде. Табигать беркайчан да үзенә ярдәм иткәннәргә җавапсыз калмый, рәхмәт әйтү чарасын ничек тә таба икән!

● Премьера

# «Балкыш»лар балкышы

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Казан федераль университеты Яр Чаллы филиалының «Балкыш» театры биредә төрле факультетларда белем алучы иң актив, милли мәдәниятне, иҗатны яратучы студентларны берләштерә.

Үз эшчәнлеген 2005 елда башлап җибәргән театрны талантлы режиссер, республика күләмендәге күпсанлы конкурслар лауреаты Факия Шәйхуллина җитәкли. Коллектив уку йорты дәрәҗәсендә генә чыгыш ясап чикләнми. Шәһәр, республика күләмендәге чараларда да бик теләп катнаша һәм уңышлары мактанырлык. Алар танылган драматургларыбыз әсәрләрен генә түгел, хәтта студентлар язган пьесаларны да сәхнәләштерәләр. Филиалда хәйрия эшләренә дә зур игътибар бирелә. Мондый чаралардан да театр артистлары читтә калмый. Сарман һәм Тукай районнары халкын да хәйрия театрлары куеп сөендереп торалар. Заман проблемаларын, яшьләр темасын яктырткан әсәрләрне сәхнәләштерү өчен зур тәҗрибә, осталык кирәк. Җитәкче белән студент бер-берсен аңлап эшләгәндә уңышка ирешү бик җиңел.

Шушы көннәрдә генә «Балкыш» театры Яр Чаллы шәһәренең Татар дәүләт драма театры сәхнәсендә чыгыш ясады. Алар тамашачы игътибарына Дамир Шәйхетдиннең «Нәүмизләр» спектаклен тәкъдим итте. Премьера ВИЧ/СПИД инфекциясен таратуга каршы оештырылган республика программасы кысаларында куелды. Рольләрне студентлар белән бергә шәһәр яшьләре дә башкарды. Премьера тамашачы тарафыннан бик җылы кабул ителде һәм шәһәрнең СПИД-үзәге тарафыннан диплом белән бүләкләнде.

«Мин укучыларымны сәхнәдә дә тормыштагы кебек сөйләшергә, үзүзләрен иркен тотарга өйрәтәм. Ясалма уйнауны яратмыйм. Студентларыбыз бик тырыш, укуга зыян китермәскә тырышалар. Алар, театрга йөреп, тормышта лидер булырга, җитәкчелек сыйфатларына өйрәнәләр. Беренче курста йомылып йөргән татар балалары биредә чәчәкләр кебек ачыла, талантларын күрсәтә», – ди җитәкчеләре Факия Шәйхуллина.

Бер генә премьера белән чикләнеп калырга уйламый театр осталары. Бүгенге көндә аларның инде сәхнәгә куярдай спектакльләре әзер. «Балкыш» театр артистлары Казан сәхнәсендә дә балкыр дип уйлыйбыз һәм аларга зур уңышлар телибез!



К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» спектакленнән бер күренеш

● Галимнәребез

# Мәшһүрлек

Динә МӨХТӘСИПОВА,
хәбәрче

Казан университетында белем алып, бөтен дөньяга танылган милләттәш-галимнәребез чиксез күп. Алар белән таныштыруны дәвам итәбез.

Корбан Галимов Киров өлкәсе Нократ Аланы районының Сасмак авылында туа. 1909 елда Малмыж шәһәрендәге педагогия техникумын тәмамлаганнан соң, Чуаш АССР мәктәпләренең берсендә математика һәм рус теле буенча дәресләр бирә.

1930 елда Казан университетының физика-математика факультетына укырга керә һәм шул вакыттан алып аның бөтен тормышы, иҗади эшчәнлеге өзлексез рәвештә университет белән бәйле. Укыган чорда ук фәнни эш белән шөгыльләнгән студентны КДУның теоретик механика кафедрасы каршындагы аспирантурада калдыралар. Аңа тәкъдим ителгән фәнни тема пластиклык теориясенең яссы мәсьәләсен чишүгә карый. Бу өлкә буенча фәнни мәктәпләр дә, юнәлешләр дә, фәнни әдәбият та бөтенләй булмый. Мондый шартларда югары дәрәҗәле теоретик эзләнүләр алып бару өчен зур сәләт кирәк була. Корбан Галимов алдына куйган максатына ирешә.

1941 елда башланган Бөек Ватан сугышы елларында Корбан Закир улы университетта зур педагогик эш белән шөгыльләнә: теоретик механика, математик физика, эластиклык теориясе һ.б. фәннәр буенча лекцияләр укый.

Тикшеренүләренең нәтиҗәсе буларак, Корбан Галимов өлкән дусты Хәмит Мөштәри белән берлектә зур күләмле хезмәт бастыра. Хезмәт аның докторлык диссертациясенә нигез була. 1960 елда Корбан Галимовка рәсми рәвештә профессор дәрәҗәсе бирелә. Ул бездә һәм чит илләрдә эластиклыкның һәм кабырчыкның нәсызыкча теорияләренә иң әүвәл нигез салучыларның берсе буларак билгеле. Галим 85 гыйльми хезмәт авторы, аның укучылары һәм эшен дәвам иттерүче шәкертләре бихисап. Корбан Галимов җитәкчелегендә Казанда 8 доктор, 50 дән артык фән кандидаты әзерләнә.



■ Рәсемдә: Корбан Галимов (беренче рәттә уртада) хезмәттәшләре белән

Корбан Галимовның вакыты гел тыгыз була. Ул һәрчак: «Студентлар көтә, кафедра көтә, Мәскәү көтә, заводлар көтә», – дияргә ярата. 1969 елда Кояш Тимбикова: «Эластик кабырчыкның нәсызыкча теориясе» дип аталган китап безнең илдә генә түгел, күп кенә чит ил галимнәре өчен дә зур вакыйгага әйләнә. Китап, инглиз теленә тәрҗемә ителеп, чит илләрдә дә ике мәртәбә басыла.

Корбан ага үзенә килгән хатларны, чакыру кәгазьләрен караштырып чыга да үзалдына елмаеп куя:

– Боларның барын да канәгатьләндереп бетерсәң, эшләргә бер дә вакыт калмас иде, – ди. – Адресларына гына күз салыгыз: Япония, Румыния, АКШ, Польша...» – дип яза бер мәкаләсендә.

Корбан Закир улы Галимовның фән һәм җәмәгатьчелек өлкәсендәге эшләре югары бәясен алды.

*(«Мәшһүр татар галимнәре» китабы файдаланылды).*


● Өйрәтәләр мәктәпләрдә

# Яңа стандартларны каршылап...

Сиринә ТРОФИМОВА,
хәбәрче

КФУның Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен камилләштерү һәм яңадан әзерләү үзәге һәрвакыттагыча гөрләп тора. Бу көннәрдә ике атнага (72 сәгатькә исәпләнгән курсларга) Татарстан Республикасының төрле районнарыннан рәсем сәнгатен укытучылар да җыелды.

Курс өчен әзерләнгән программа һәм тематик планда теория белән бергә гамәли эшләр тигез каралган. Шундый гамәли эшләрнең берсе башкалабыздагы Яңа Савин районының 146 нчы урта мәктәбендә үткәрелгән «Яңа Дәүләт Федераль белем бирү стандартын гамәлгә кертү шартларында рәсем сәнгате дәресләренең эчтәлеген яңарту» дигән семинар-практикум булды.





«Россиянең иң яхшы мәктәпләре – 2008» конкурсы җиңүчесе булган бу мәктәп үзенең заманчалыгы, затлылыгы, уңайлылыгы белән аерылып тора.

40 сыйныфтан торган 1058 укучылык мәктәп бер генә сменада эшли. Монда үз эшенең остасы булган, хәзерге көн мәгълүмати технологияләрен яхшы белгән 70 иҗади укытучы белем бирә. Коллективның 65% югары һәм беренче категориягә ия, 3 педагог – фәннәр кандидаты. 1 педагоглары «Соросов укытучысы» гранты белән бүләкләнгән. Шулай ук 5 мөгаллим – «Безнең иң яхшы укытучы», 1 мөгаллим – «Безнең яңа укытучы» гранты җиңүчеләре. Мәктәп директоры – югары категорияле җитәкче, педагогика фәннәре кандидаты, белем бирү менеджеры, «Укытучы-тикшеренүче – 2011» гранты иясе Диләрә Салих кызы Кәримова.

Балалар тарафыннан эшләнгән «Халык сәнгате» рәсемнәр күргәзмәсен карагач, Диләрә ханым «Позитив үзгәрешләр стратегиясе» дип аталган презентация белән чараны ачып җибәрде. Директор урынбасарлары Ольга Константинова һәм Светлана Павлованың «Яңа дәүләт стандартларын гамәлгә кертү шартларында рәсем сәнгате дәресләренең эчтәлеген яңарту», «Федераль дәүләт стандартларын реализацияләү шартлары» турындагы чыгышлары укытучыларда зур кызыксыну уятты.

I «Д» сыйныфында – Эльмира Колоярцева һәм V «А» сыйныфында Эльмира Абдуллина тарафыннан үткәрелгән дәресләрне семинарда катнашучылар югары бәяләде. Түгәрәк өстәл янында сөйләшү дә укытучылар өчен әһәмиятле булды. Мәктәпнең «Үзебезне ачкан саен, дөньяны камилләштерәбез» дигән девизы бу белем учагының заманча белем бирүе һәм яшәү рәвеше алып баруы турында сөйли. Аның яңа дәүләт стандартларын кабул итәргә әзер булуы кунакларны тагын да сокландырды.

● Юксыну

# Ул тормышны яратты

Динара ӘХМӘТОВА,
хәбәрче

«Нинди генә очракларда да кеше булып кала алу һәм намуска тап төшермәү» аның төп девизы иде. Ул шулай яшәде дә... Олыны олы, кечене кече итте, һәркемгә ярдәм кулы сузарга ашыкты. Үзе безнең арабызда булмаса да, аның иҗаты мәңге яшәячәк!



■ Рәсемдә: автор (уртада) Нурсөя һәм Фәнис Яруллиннар белән

*Шушы көннәрдә халкыбызның хөрмәтле шәхесе, яраткан шагыйребез, язучы, драматург, балалар язучысы Фәнис Яруллин вафат булды.*

*Аның иҗатын белмәгән, яратмаган кеше юктыр. Гадилеге, самимилеге белән укучының күңелен яулап ала. Әсәрләрендә халык өчен якын, актуаль проблемалар үзәккә чыга. Сюжетка салынган вакыйгаларның һәркайсы реаль, тормыштан алынган.*

*Язмыш аның үзенә дә зур сынаулар җибәрә шул. Яшьли урын өстендә калган егетнең рухи көче нык була. Озак еллар урын өстендә, больницаларда дәваланып ятуына карамастан, Ф.Яруллин бөтен тырышлыгын, рухи көчен белем дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби иҗат эшенең серләрен үзләштерүгә юнәлтә: 1963 елда экстерн тәртибендә урта мәктәп программасы буенча имтихан тота, 1970 елда исә, читтән торып укып, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый.*

*Фәнис абый белән мин дүрт ел таныш идем. Балачактан ук шигырьләрен укып хисләнгән кеше буларак, аның белән шәхсән танышу мөмкинлеген кулдан ычкындырмадым. Беренче күрешүдә үк без күптәнге танышлар кебек аралаштык, сөйләшер сүзләребез бетмәде. Янына килгән һәр кеше белән матур итеп аралаша, моң-зарларын тыңлый иде. Ә үзенең беркайчан да тормыштан зарланганы, кемнедер мыскыл итеп, начар сүз сөйләгәне булмады.*

*Шат күңелле Фәнис абыйның яшь кызларны ратканын һәркемнең ишеткәне булгандыр. Иҗат кешесе өчен бу табигый әйбер. Сеңлем белән танышканчы, мине дә бик яратты Фәнис абый. Безгә багышлап бик күп шигырьләр иҗат итте. Әле көз айларында гына дөнья күргән җыентыгында шул иҗат җимешләренең урын алуы безнең өчен иң зур һәм кадерле бүләк булды.*

*Фәнис абыйның бу җирдә яшәп, шундый зур уңышка, дәрәҗәгә ирешә алуында Нурсөя апаның өлеше зур. Гомер юлдашы өчен җанынтәнен бирергә әзер иде ханым. Нурсөя апа хәл белергә килгән кешене һәрвакыт ягымлы карашы, назлы сүзләре, җылы чәе һәм тәм-томнары белән каршы алды. Урын өстендә яткан Фәнис абыйны илһамландыручы да, иҗат җимешләрен халык хозурына җиткерүче дә Нурсөя апа булды. Аларның саф мәхәббәтенә, гаилә ныклыгына сокланмый мөмкин түгел. Бүгенге яшьләр өчен — алар үрнәк.*

*Фәнис абый Яруллин иҗаты шактый өйрәнелгән, анализланган. Әле быел гына яклаган диплом эшемнең аның драматургиясенә багышлануы да минем өчен зур бәхет булды. Иң мөһиме: Фәнис абый аның белән үзе танышып барды һәм югары бәяләде. Тел һәм әдәбият белгечләре алга таба әлеге бай хәзинәдән тагын да яңа, кыйммәтле җәүһәрләр табар дип уйлыйм. Чөнки Фәнис абый еш кына: «Минем иҗатны әле тикшерәсе дә тикшерәсе, төп идеяне ачып бетерә алмыйлар», — дия иде.*

*Үзе арабызда булмаса да, татар халкының бөек улы Фәнис Яруллин иҗаты мәңгелек. Без аны буыннан-буынга тапшырырбыз, сакларбыз. Тыныч йоклагыз, Фәнис абый, урыныгыз оҗмах түрләрендә булсын!*

• Халәт

# Илһам ишек какканда...

**Алсу НУРГАТИНА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

ШИГЫРЬЛӘРНЕ КАЙЧАН ЯЗА БАШЛАВЫМНЫ ЯХШЫ ХӘТЕРЛИМ. ДҮРТЕНЧЕ СЫЙНЫФТА УКЫГАНДА, «ДУСЛЫК ИЛЕНДӘ» ДИП АТАЛГАН ӨЧ КУПЛЕТЛЫ ТӘҮГЕ ШИГЫРЕМНЕ ЯЗГАН ИДЕМ. БЕР КӨТҮ СҮЗЛӘР ӨЕМЕ, АРА-ТИРӘ РИФМАЛАР ШӘЙЛӘНӘ.



Әнинең, моны күреп, чын күңелдән сөенгәнен хәтерлим. Бүген инде шактый эчтәлекле шигырьләрем белән төрле конкурсларда урыннар алгалыйм. Элек һәм хәзер язган шигырьләрне чагыштырып та булмый. Балачактагы дәфтәрләргә теркәп барган шигырьләрне укыганда, чын күңелдән көлдерә. Ләкин бер туктамыйча язып торуым минем үсешемә ярдәм иткән. Шигъри юлымның нигезе – әнә шушы шигырьләрдә.

Мине журналистика дөньясына алып кергән Илфат абый Фәйзрахмановның әйткән сүзләре яхшы хәтердә: «Гади кеше лирик җаннан ничек аерыла?! Мәсәлән, яңгыр явып узгач туган күлләвекне күрмичә, гади кеше игътибарсыз гына китеп бара. Ә лирик көндез болытларны, кояшны күрә, ә төнлә ай, йолдызлар шәүләсенә сөенә». Бу сүзләр белән, һичшиксез, килешәм. Әйләнә-тирә дөньябызда юк кына нәрсәдән дә шундый могҗиза таба белү, әлбәттә, һәркемгә дә бирелми шул. Кайвакыт, төрле кызык хәлләргә дә юлыгып куясың. Шигырь бит ул үз тормышыңнан гына түгел, ә, бәлки, чит кешене күзәтеп, гыйбрәтле язмышларга күз салып та языла. Автор һәм лирик герой – икесе ике кеше. Минем ирсез бала тапкан, ялгыз гына кызын тәрбияләүче ана кеше турында «Кызыма» дип исемләнгән бер шигырем бар иде. Ул матбугатта дөнья күргәч, бер апа шалтыратты. «Балам, синең кызың бар икән. Бик яшьли тапкансың шул. Әйдә, төгәл адресыңны әйт, үзем ничек булдыра алам, шулай ярдәм итәрмен», - ди. Апага барсын да аңлатып бирергә туры килде. Лирик геройның күңел өземтәсе булуына төшендергәч, трубканы куйдым. Әлбәттә, шундый киң күңелле кешеләр булуга сөенәм. Шулай ук «Алпан-тилпән атлап караңгы урамнан...» – дип башланган шигырьгә бәйле шалтыратучылар да күп булды. «Ничек шул галәмәт эчәргә кирәк, аннан әле үзе шуны язып та чыгара», – дип сүктеләр. ...Аңлатырга туры килде.

Лирик кешенең күңеле башка төрле ул. Минем, мәсәлән, кайвакыт гади бер сүздән дә күңелдә давыл кузгалып, әсәр языла. Ул бит синең үзеңнән генә тормый, нишлисең, күңел нечкәлеге шундый. Төрле кешеләрнең бәясе төрлечә була. Ара-тирә тәнкыйтьләүчеләр дә очрый. Монысына да күңел сөенә. Иҗатта ул беренче урында, иҗатны үстерергә мөмкинлек бирә.

Бүгенге көндә иҗат ишекләрен әле яңа гына ачарга маташучылар күптер. Иң мөһиме: күңел төшенкелегенә бирешмәгез, иҗат итегез. Төрле әйтелгән сүзләргә карап, каләмегезне ташламагыз. Һәркемгә дә иҗатка юллар киң ачык!..

***P.S.*** Барлык яшь иҗатчыларга да чын күңелдән уңышлар телим!

• Тәңгә – мунча, җанга – юк

# Калагамы? Салагамы?

**Гөлназ ГАТАУЛЛИНА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Шәһәр яшьләрнең күбесен үзенә тартып тора. Мәктәпне тәмамлаган күп укучылар белем, эш артыннан шунда юллана. Аларга шәһәр тормышы авылныкына караганда рәхәтрәк, кызыграк, иркенрәк тоела. Ләкин, дөресен генә әйткәндә, монда безне берсе дә колач җәеп каршы алмый. Син үзаллы яшәргә тиеш, биредә әти дә, әни дә юк! Баштагы елларда авыл баласына авыр булса да, соңрак өйрәнеп китәсең. Хәтта шау-гөр килеп торган шәһәр тормышы «үтереп» ошый башлый һәм синең ары таба бары тик шәһәрдә яшисең килә.

Беренче ел укый башлаган студентка шәһәр тормышының капкасы серле дөнья кебек. Ул әкренләп аның таләпләренә буйсына.

Шәһәр безне үзгәртә. Галимнәр фикеренчә, шәһәргә яшәргә килгән кешеләрнең хәл-торышы, кыяфәте, холкы 50 процентка үзгәрә.

***Яхшы якка үзгәрү:***

1. Син мөстәкыйль тормыш башларга әзер була аласың. Һәр очраган каршылыкларны дөрес чишеп, акыллы уй-фикергә килергә, җәмгыятьтә үзеңне тотарга өйрәнәсең.
2. Әдәп һәм тәрбия якларына килгәндә, син күпкә акыллы кыяфәт белән йөри аласың, чөнки хәзер син шәһәр кешесе. Моңа театрлар, концертлар, төрле җәмәгать урыннарының тәэсире зур.
3. Әгәр дә син, үз көчеңә һәм эшли алырыңа ышанып, укыган вакытта берәр җирдә эшләп тә йөрсәң, бу бик яхшы.

***Кире якка үзгәрү:***

1. Шәһәрнең бозылуга этәрүе ихтимал. Ул сине, коткыга салып, вәсвәсәләндерергә мөмкин. Аның күңелне кызыктырган мавыктыргыч «әйберләре» бихисап. Әгәр дә башыңда җил уйнаса, күңелле компанияләр сине эчүгә, тәмәке тартуга, наркотиклар куллануга һ.б. бозыклыкларга алып килергә дә күп сорамас.
2. Уйда бер генә нәрсә – эти-әниеңнең сине акча белән тәэмин итә алуы көн кебек ачык. Һәм ул акчаларны рәхәтләндереп туздырырга була. Ә бу исә, үз чиратында, кешене ялкаулыкка китерә.
3. Шәһәр мохите яшьләрнең нерв системасын какшата. Монда сулаган һава да зарарлы. Аның составында төрле химик матдәләр күп. Болар барысы да организмга зыян сала.
4. Шәһәр яшьләрнең холкын ныгытса да, шул ук вакытта аны әрсез, тупас, усал булырга өйрәтә.

Шәһәрнең кире һәм уңай якларын үзләштерү-үзләштермәү һәм киләчәктә шәһәрнең ыгы-зыгысынмы яки авылның тыныч тормышын сайлаумы – болар һәркемнең шәхси эше. Әмма вакыт үтү белән, шул ачыклана: кала тормышы анда яшәгән кешегә тәэсир итми калмый.

• Спорт

# Теләк кирәк

**Рәзил КАШАПОВ,**
татар филологиясе
бүлеге студенты

УЗГАН АЙЛАРДА КӨНЬЯК КОРЕЯНЫҢ ТӘГУ КАЛАСЫНДА ҖИҢЕЛ АТЛЕТИКА БУЕНЧА ДӨНЬЯ БЕРЕНЧЕЛЕГЕ ҮТКӨРЕЛДЕ. БУ ЯРЫШЛАР БИГРӘК ТӘ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ БУЛДЫ. ЧӨНКИ ЙӨГЕРҮ ЯРЫШЛАРЫНДА КӨНЬЯК АФРИКА РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АЯКСЫЗ СПОРТЧЫСЫ ОСКАР ПИСТОРИУС КАТНАШТЫ. ПРОФЕССИОНАЛЬ СПОРТТА, ШУЛАЙ УК ҖИҢЕЛ АТЛЕТИКАДА БУ БЕРЕНЧЕ ХӘЛ.





Аның язмышы күп кешедә җәлләү хисе уята. Туып, унбер ай үткәч, табиблар малайның аякларын тездән түбән кисәргә мәҗбүр була. Бу хәл аны туктатмый. Ярым сәламәт килеш Оскар, гәдәти урта мәктәптә белем алып, регби, теннис, ватерполо һәм хәтта ирекле көрәштә дә үзен сынап карый. Ләкин спортның йөгерү төренә аның мәхәббәте көчлерәк була.

Хәзер спортчының Дөнья беренчелегендә һәм Олимпия уеннарында катнашырга мөмкинлеге бар. Күпләр гаҗәпләнер: Оскар, Италиянең Линьяно бистәсендә үткән ярышларда катнашып, 400 м аралыкны 45,07 секунд эчендә килеп, I урынны яулады. Шул уңышы аркасында аңа Писториуста иң мөһим ярышларда катнашырга рөхсәт ителде. Ә IAAF җәмгыяте бервакыт Оскарга сәламәт спортчылар белән бер ярышта катнашуны тыйган, чөнки карбоннан ясалган җайланмалары йөгергәндә аңа өстенлек бирә икән. Ләкин ул Лозанна бистәсендә урнашкан Спорт эшләре буенча арбитраж суды (CAS, TAS) вәкилләренә барып: «Бу җайланмалар старт алганда кузгалып китәргә комачаулый, киресенчә, тизлек югала», – дип ситуацияне аңлата.

Оскар Писториус хакында өстәп тагын шуны әйтәсе килә: бу кешегә карап горурланасың. Спорт белән шундый хәлдә дә шөгыльләнүчеләр күпме? Минемчә, Оскар өчен йөгерү белән шөгыльләнү алтын-көмешләрдән кадерлерәк. Бу кешедән үрнәк алып, сәламәт яшәү рәвешен алып барыйк һәм спорт белән шөгыльләник!

• Дөнья үзебезнеке

# Газап китә, ярату кала



**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

*(Дәвамы. Башы 10 нчы санда)*

Кайчан гына булмасын, әтием миңа мөрәҗәгать иткәндә сүзен: «Бүген мин сиңа яратуым турында әйттемме әле?» – дип башлый иде. Бу рәвешле ярату белдерү ике яклы булып, ул бик картайгач та, вафатына санаулы көннәр калган вакытта да туктамады.

82 яшендә ул үлемгә әзер иде, ә мин, аның җәфалануларын күреп, соңгы юлга китәчәге белән килешкән идем. Без көлдек тә, еладык та. Вакытның якынлашуын сизеп, кулларыбыздан тотынышып, бер-беребезне яратуыбызны белдердек. «Әтием, – дидем мин аңа шул чагында, – син бөтенләйгә киткәч, миңа аннан берәр билге җибәрерсең әле, яме». Ул көлеп куйды, чөнки беркайчан да реинкарнациягә ышанмады. Тик «теге дөнья»дан сигнал алу мөмкинлеге булуга минем тормышта ышандырырлык мисаллар бар иде.

Безнең арада зур элемтә булганлыктандыр, әтием күзләрен мәңгелеккә йомган мизгелдә мин йөрәгемдә көчле авырту тойдым. Госпиталь хезмәткәрләренең әтиемнең соңгы минутларында кулын тотып торырга рөхсәт итмәүләренә өзгәләндем.

Көн саен аңардан хәбәр көттем, тик юкка гына. Төшемә керүен сорадым. Дүрт ай үтеп китте, югалту ачысыннан башка нәрсә сизмәдем. Мин, җиткән ике кыз үстергән кеше, 5 ел элек альцгеймер авыруыннан әнием үлеп киткәч, үземне тома ятим итеп сизгән идем.

Бервакыт караңгы, тыныч бүлмәнең массаж өстәлендә билгеләнгән сеансны көтеп ятканда, мине әтине сагыну хисе биләп алды. Аңардан нинди дә булса билге җибәрүен таләп итүем бик катгый булмадымы икән, дигән сорау уйдан чыкмады. Бу вакытта баш миенең аеруча сизгер халәттә булуын һәм акылның күнегелмәгән ачыклыгын искәрдем. Һәр фикерем тыныч су өстенә тамган тамчыга охшаган иде һәм һәр узып баручы мизгелнең тынычлыгы, хәрәкәтсезлеге белән ләззәтләнә идем. Шул вакытта моңа кадәр читтән килгән һәр хәбәрне тикшереп торырга тырышуым, моннан соң алай эшләмәячәгем турында уйлап алдым. Көтмәгәндә, каршыма әниемнең альцгеймер авыруы аның зиһенен, кеше кыяфәтен һәм 50 фунт авырлыгын алганчыга кадәр булган йөз кыяфәте килеп басты. Аның сөйкемле битендә куе калын чәчләре дулкынланып торалар иде – кулымны сузсам, аңа кагылырмын сыман иде. Ул миңа күп еллар элек караган кебек карап торды. Хәтта яраткан исле мае – «Джой» исен тойдым. Әнием, нәрсәдер көткән кебек, бер сүз дә әйтмәде.

Ничек шулай килеп чыкканын мин аңлап җиткермәдем – әти турында уйладым, ләкин әнине күрдем. Аның да яныма килүен сорамавым өчен бик оялдым. «Их, әни, – дип эндәштем мин, – бик аяныч, сиңа шундый коточкыч авыру белән җәфаланырга туры килде». Сүзләремне аңламагандай, башын әкрен генә кырын салды. Үзенең искиткеч гаҗәеп елмаюы белән елмайды да: «Минем исемдә калган бөтен нәрсә – ярату», – диде. Аннан соң юкка чыкты. Миңа кинәт кенә салкын булып китте, калтырый башладым. Шунда бөтен барлыгым белән аңладым: без башкалардан алган һәм башкаларга биргән мәхәббәт, ярату – әһәмияткә ия булганның барысы да – хәтердә кала. Газаплар китә, ярату кала. Гомеремдә ишеткән барлык сүзләр арасында әниемнең әлеге сүзләре иң мөһиме булды. Шул вакыттан бирле алар йөрәгемдә мәңгегә калды.

Миңа әлегә кадәр әтиемне күрергә, тавышын ишетергә насыйп булмады. Ләкин кайчан да булса, һич көтмәгәндә, аны күрәчәгемә ышанам. Ул килер һәм: «Бүген мин сиңа яратуымны әйттемме әле?» – дияр.

*(Бобби Пробштейн)*

(дәвамы бар)

(Дж. Кэнфилд һәм М.В.Хансен хезмәтләре файдаланылды).

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева, Б.Х.Ибраһимов, Э.Р.Ибраһимова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла